КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 8 сентябрь г.Казань № 808

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 27 апрель, 340 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә

торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 27 апрель, 340 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 август, 707 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларының медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибен һәм 2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен шәхси медицина оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»;

1 нче пунктта:

икенче абзацта «медицина хезмәткәрләренә» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларының» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен шәхси медицина оешмаларына субсидияләр бирү тәртибе.»;

әлеге карар белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе исеменә «медицина хезмәткәрләренә» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларының» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган

төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибенең 3 пунктына «бюджет һәм автоном учреждениеләр» сүзләреннән соң «, шәхси медицина оешмалары» сүзләрен өстәргә;

әлеге карарга 2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен шәхси медицина оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 30 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 8 сентябрь, 808 нче
карары белән расланды

2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен шәхси медицина оешмаларына субсидияләр бирү
тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип 2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен шәхси медицина оешмаларына субсидияләр бирүнең (алга таба – субсидияләр) гомуми нигезләмәләрен, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Субсидияләр алу хокукына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруын профилактикалау һәм тарату рискын киметү буенча чараларны тормышка ашыру максатларында медицина оешмалары эшен оештыруның вакытлыча тәртибе турында» 2020 елның 19 мартындагы 198н номерлы боерыгы белән расланган COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруын профилактикалау һәм тарату рискын киметү буенча чараларны тормышка ашыру максатларында медицина оешмалары эшен оештыруның вакытлыча тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга беренчел медицина-санитария ярдәмен, стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәмен, ашыгыч медицина ярдәмен фактта күрсәтүче шәхси медицина оешмалары (алга таба – шәхси медицина оешмалары) ия.

1.3. Субсидияләр яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу (шул исәптән тулы күләмдә) максатларында Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган федераль бюджет акчасы исәбеннән бирелә.

1.4. Субсидияләр яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне (алга таба – кызыксындыру характерындагы түләүләр) гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен шәхси медицина оешмаларына бирелә.

1.5. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

1.6. Акчаны тоту Министрлык тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

1.7. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен, алар Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгәннән соң, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Министрлыкка җиткерә.

## II. Субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидияләр бирү шартлары:

2.1.1. Субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның 1есенә шәхси медицина оешмасының түбәндәге таләпләргә туры килүе:

шәхси медицина оешмасы билгеләнгән тәртиптә теркәлергә һәм эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырырга тиеш;

шәхси медицина оешмасы чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория торган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булып тормый;

шәхси медицина оешмасы әлеге Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормый;

шәхси медицина оешмасының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

шәхси медицина оешмасының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

шәхси медицина оешмасы үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы башланмау, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау.

2.1.2. Татарстан Республикасы территориясендә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемдәге затларга беренчел медик-санитар ярдәм, стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәмен, ашыгыч медицина ярдәмен фактта күрсәтү.

2.1.3. Шәхси медицина оешмасының Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан шәхси медицина оешмасының субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәвенә тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

2.1.4. Шәхси медицина оешмасы тарафыннан алынган чит ил валютасы акчасы исәбеннән сатып алуга (югары технологияле чит ил җиһазлары, чималы һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) тыюны үтәү йөкләмәсе.

2.2. Шәхси медицина оешмасына ай саен бирелә торган субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = C_p + C_n + C_m,$$

монда:

$C_p$ – хисап ае өчен беренчел медик-санитар ярдәм күрсәткәндә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирүгә акча күләме;

$C_n$ – хисап ае өчен стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәткәндә кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирүгә акча күләме;

$C_n$ – хисап ае өчен ашыгыч медицина ярдәме күрсәткәндә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирүгә акча күләме.

Хисап ае өчен беренчел медик-санитар ярдәм күрсәткәндә кызыксындыру характердагы түләүләр бирүгә акча күләме ($C_p$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_p = (V_p \times S_v + S_p \times S_s + M_p \times S_m) \times 1{,}302,$$

монда:

$V_p$ – хисап ае өчен яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче югары (медицина булмаган) белемле табиблар һәм медицина хезмәткәрләре саны;

$S_v$ – фактта эшләгән вакыт эчендә биләгән вазыйфа нигезендә беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче югары (медицина булмаган) белемле табибларга һәм медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы, әмма 25 919,2 сумнан артмаган түләү күләме;

$S_p$ – хисап ае өчен яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүдә катнашучы урта медицина персоналы саны;

$S_p$ – фактта эшләгән вакыт эчендә биләгән вазыйфа нигезендә беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүдә  катнашучы урта медицина персоналына кызыксындыру характерындагы, әмма 12 959,6 сумнан артмаган түләү күләме;

$S_p$ – хисап ае өчен яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүдә катнашу өчен шартлар тәэмин итүче кече медицина персоналы саны;

$S_m$ – фактта эшләгән вакыт эчендә биләгән вазыйфа нигезендә беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтү өчен шартлар тәэмин итүче кече медицина персоналына кызыксындыру характерындагы, әмма 6 479,8 сумнан артмаган түләү күләме;

1,302 – Россия Федерациясе законнары нигезендә эш хакына исәпләүләр коэффициенты.

Хисап ае өчен стационар шартларда (Cn) махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәткәндә кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирүгә акча күләме ($C_n$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_n = (V_n \times S_b + S_n \times S_c + M_n \times S_l) \times 1{,}302,$$

монда:

$V_n$ – хисап ае өчен яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче югары (медицина булмаган) белемле табиблар һәм медицина хезмәткәрләре саны;

$S_b$ – фактта эшләгән вакыт эчендә биләгән вазыйфа нигезендә стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүче югары (медицина булмаган) белемле табибларга һәм медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы, әмма 32 399,0 сумнан артмаган түләү күләме;

$V_n$ – хисап ае өчен яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүдә катнашучы урта медицина персоналы саны;

$S_c$ –  фактта эшләгән вакыт эчендә биләгән вазыйфа нигезендә стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтүдә катнашучы урта медицина персоналына кызыксындыру характерындагы, әмма 16 199,5 сумнан артмаган түләү күләме;

$M_n$ – хисап ае өчен яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тәэмин итүче кече медицина персоналы саны;

$V_n$ – фактта эшләгән вакыт эчендә биләгән вазыйфа нигезендә стационар шартларда махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тәэмин итүче кече медицина персоналына кызыксындыру характерындагы, әмма 9 719,7 сумнан артмаган түләү күләме;

1,302 – Россия Федерациясе законнары нигезендә эш хакына исәпләүләр коэффициенты.

Хисап ае өчен ашыгыч медицина ярдәме күрсәткәндә кызыксындыру характерындагы түләүләр бирүгә акча күләме ($C_m$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C_m = (V_m \times S_k + S_m \times S_r + F_m \times S_t) \times 1{,}302,$$

монда:

$V_m$ – хисап ае өчен яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүче табиблар саны;

$S_k$ – фактта эшләгән вакыт эчендә билгән вазыйфа нигезендә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүче табибларга кызыксындыру характерындагы, әмма 25 919,2 сумнан да артмаган түләү күләме;

$S_m$ – хисап ае өчен яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүдә катнашучы урта медицина персоналы саны;

$S_r$ – фактта эшләгән вакыт эчендә билгән вазыйфа нигезендә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүдә катнашучы урта медицина персоналына кызыксындыру характерындагы, әмма 12 959,6 сумнан артмаган түләү күләме;

$F_m$ – хисап ае өчен ашыгыч медицина ярдәме чакыруларын кабул итү һәм аларны күчмә ашыгыч медицина ярдәме бригадаларына тапшыру буенча фельдшерлар (шәфкать туташлары) саны;

$S_t$ – фактта эшләгән вакыт эчендә билгән вазыйфа нигезендә ашыгыч медицина ярдәме чакыруларын кабул итү һәм аларны күчмә ашыгыч медицина ярдәме бригадаларына тапшыру буенча фельдшерларга (шәфкать туташларына), әмма 6 479,8 сумнан да артмаган түләү күләме.

Хисап ае өчен шәхси медицина оешмасының медицина һәм башка хезмәткәрләре саны әлеге Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә шәхси медицина оешмасы тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә билгеләнә.

2.3. Субсидия алу өчен шәхси медицина оешмасы, түбәндәгеләрне теркәп, Министрлыкка субсидия бирү турында гариза тапшыра:

1) салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсе;

2) Юридик затларның бердәм дәүләт реестры язмасы бите күчермәсе;

3) субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның беренче көне хәленә карата Россия Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада тапшыру форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча белешмә кәгазе;

4) шәхси медицина оешмасы җитәкчесе һәм баш бухгалтерының имзасы куелган, мөһере (мөһере булганда) белән расланган субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау турында белешмә кәгазе (ирекле формада);

5) шәхси медицина оешмасы җитәкчесенең имзасы куелган, мөһере (мөһере булганда) белән расланган шәхси медицина оешмасының үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы башланмавын, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын раслый торган белешмә кәгазе;

6) шәхси медицина оешмасы җитәкчесенең имзасы куелган, мөһере (мөһере булганда) белән расланган шәхси медицина оешмасының чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

7) шәхси медицина оешмасы җитәкчесе һәм баш бухгалтерының имзасы куелган, мөһере (мөһере булганда) белән расланган шәхси медицина оешмасының әлеге Тәртипнең 1.4 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын раслый торган белешмә кәгазе;

8) шәхси медицина оешмасының яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина һәм башка хезмәткәрләре саны турында белешмә кәгазе; анда вазыйфасы, шәхси медицина оешмасының аларда эшләү кызыксындыру характерындагы түләүләрне билгеләүгә хокук бирә торган структур бүлекчәсе күрсәтелә;

9) әлеге Тәртипнең 2.2 пункты нигезендә субсидия күләменең исәп-хисабы;

10) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 27 апрель, 340 нчы карары белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне бирү тәртибенең 3 пункты таләпләре нигезендә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнар булуга бәйле рәвештә кабул ителә торган, шәхси медицина оешмасы тарафыннан расланган локаль норматив акт күчермәсе.

2.4. Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документлар шәхси медицина оешмасы тарафыннан Министрлыкка кәгазьдә тапшырыла.

Хосусый медицина оешмасы тарафыннан әлеге Тәртипнең 2.3 пунктындагы 1 – 2 пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктының 3 – 9 пунктчаларында күрсәтелгән документлар субсидия бирү турында гариза җибәргәндә шәхси медицина оешмасы тарафыннан ай саен тапшырыла.

Әлеге Тәртипнең 2.3 пунктындагы 1, 2, 10 пунктларында күрсәтелгән документлар шәхси медицина оешмасының беренче тапкыр мөрәҗәгать итүе белән Министрлыкка тапшырыла.

Шәхси медицина оешмасы бирелә торган мәгълүматларның һәм тапшырыла торган документларның дөреслеге һәм тулылыгы өчен җавап бирә.

2.5. Министрлык:

кергән көнне субсидия алу турындагы гаризаларны терки;

субсидия бирү турында гариза теркәлгән көннән биш эш көне эчендә шәхси медицина оешмасы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртиптә

каралган таләпләргә туры килү-килмәвен гаризаларны теркәү чираты тәртибендә карап тикшерә, документлардагы мәгълүматның дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү турында йә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

субсидияләр бирү турында йә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә шәхси медицина оешмасына кабул ителгән карар турында хәбәр итә. Хәбәрнамә шәхси медицина оешмасының җитәкчесенә шәхсән йә аның вәкиленә ышаныч кәгазе буенча тапшырыла яки почта аша заказлы хат белән җибәрелә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән биш эш көне эчендә шәхси медицина оешмасы белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган бертип форма нигезендә Килешү төзи.

Килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, күчерү тәртибе, алучының субсидияне кире кайтару очраклары һәм тәртибе, алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю (югары технологияле чит ил җиһазы, чималы һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш), субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе, субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары, субсидия алучының Министрлык, дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы, субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең һәм төзелә торган Килешүнең шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр, Килешү шартларын бозган өчен җаваплылык карала.

2.6. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

җыелма бюджет исемлеге нигезендә агымдагы финанс елында бу максатлар өчен Министрлыкка җиткерелгән ассигнованиеләр булмау;

шәхси медицина оешмасының әлеге Тәртипнең 2.1 пунктындагы 2.1.1 – 2.1.4 пунктчаларында күрсәтелгән субсидияләр бирү таләпләренә һәм шартларына туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

шәхси медицина оешмасы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.3 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

шәхси медицина оешмасы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

2.7. Министрлык акчаны, Килешү төзегән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, үзенең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счетыннан шәхси медицина оешмасының Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә һәм кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына күчерүне гамәлгә ашыра.

2.8. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып шәхси медицина оешмаларының яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүче, әлеге Тәртип шартлары нигезендә кызыксындыру характерындагы түләүләрне алган медицина хезмәткәрләре саны тора.

## 3. Хисаплылыкка карата таләпләр

3.1. Шәхси медицина оешмасы ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтадагы форма буенча Министрлыкка шәхси медицина оешмасының финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнары турында һәм субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү хакында хисап тапшыра.

## IV. Субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга карата таләпләр һәм аларны бозган өчен җаваплылык

4.1. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары шәхси медицина оешмасының әлеге Тәртип һәм Килешү шартлары, максатлары үтәвен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

4.2. Шәхси медицина оешмасы финанс белән тәэмин итү өчен субсидия бирелә торган чыгымнарның аерым исәбен алып бара.

4.3. Агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата субсидиянең файдаланылмый калган өлеше агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидиянең файдаланылмый калган өлеше шәхси медицина оешмасы тарафыннан күрсәтелгән вакыт эчендә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелмәгән очракта, акча Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтелергә тиеш.

4.4. Субсидия шәхси медицина оешмасы тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар биргәндә һәм документлар тапшырганда;

субсидия биргәндә билгеләнгән, Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тикшерүләре фактлары буенча ачыкланган шартларны бозганда;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәгәндә;

субсидия акчасыннан максатчан файдаланмаганда.

Шәхси медицина оешмасы тарафыннан субсидияне кире кайтару вакыты бозылганда Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

Татарстан Республикасы бюджеты кеременә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

4.5. Субсидияләрдән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.6. Шәхси медицина оешмалары тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык шәхси медицина оешмаларының тиешле вазыйфаи затларына йөкләнә.

2020 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы йоктыру куркынычы янаган төркемнәрдәге затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен кызыксындыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен шәхси медицина оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта

Форма

Шәхси медицина оешмасының финанс белән тәэмин итү чыганагы
булып субсидия торган чыгымнары турында һәм
субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

Тапшыру вакыты: ай саен
Тутырыла: хисап елы башыннан арта бара торган йомгак белән.
Үлчәү берәмлеге: сум (өтердән соң икенче унарлы билгегә кадәр төгәл итеп).

1. 20__ елның «__» __________ хәленә карата
шәхси медицина оешмасының финанс белән тәэмин итү чыганагы булып
субсидия торган чыгымнары турында мәгълүматлар

| Т/с | Шәхси медицина оешмасының исеме | Хисап елы башына акчаның калган өлеше, барлыгы | Шул исәптән ихтыяҗ булуы раслаган акчаның калган өлеше | Татарстан Республикасы бюджетыннан акча керде | Касса чыгымы | Үткән еллардагы акчаның файдаланылмый калган өлеше торгызылды | Үткән еллардагы акчаның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылды | Хисап елы ахырына акчаның калган өлеше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

2. 20_ _ елның «__» __________ына(енә)
субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында мәгълүматлар

| Т/с | Шәхси медицина оешмасының исеме | Нәтиҗәнең исеме | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап датасы хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) _____________ ___________/________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

М.У.

Башкаручы _____________ __________/_________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

________________________________